КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 25 апрель г.Казань № 519

2026 елга Татарстан Республикасы бюджетыннан «Педагог – ясалма интеллект түгәрәге җитәкчесе» түләвен бирү тәртибе турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының, дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының, дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларының ясалма интеллектны өйрәтү чараларын гамәлгә ашыручы укытучыларына, мөгаллимнәренә Татарстан Республикасы бюджетыннан бер тапкыр 258 624 сум күләмендә бирелә торган «Педагог – ясалма интеллект түгәрәге җитәкчесе» түләвен билгеләргә.

2. Бу карарга теркәлгән 2026 елга Татарстан Республикасы бюджетыннан «Педагог – ясалма интеллект түгәрәге җитәкчесе» түләвен бирү тәртибен расларга.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы бюджетыннан «Педагог – ясалма интеллект түгәрәге җитәкчесе» түләвен бирү эшен оештырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 25 апрель, 519 нчы
карары белән расланды

## 2026 елга Татарстан Республикасы бюджетыннан «Педагог – ясалма интеллект түгәрәге җитәкчесе» түләвен бирү тәртибе

### I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының һәм дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының, дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларының ясалма интеллектны өйрәтү чараларын гамәлгә ашыручы укытучыларына һәм мөгаллимнәренә Татарстан Республикасы бюджетыннан «Педагог – ясалма интеллект түгәрәге җитәкчесе» түләвен (алга таба – түләү) бирү максатын, механизмын һәм шартларын билгели.

2. Әлеге Тәртиптә түбәндәге терминнар кулланыла:

түләү алырга теләүчеләр – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының, дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының һәм дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларының Россия Федерациясе гражданнарыннан педагогик эшчәнлек профиленә һәм белем бирелә торган уку-укыту предметына туры килә торган югары белеме яки урта һөнәри белеме булган укытучылары һәм мөгаллимнәре;

эш бирүче – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, хезмәт шартнамәсе буенча хезмәткәре түләү алырга дәгъва иткән дәүләт гомуми белем бирү оешмасы, муниципаль гомуми белем бирү оешмасы, дәүләт һөнәри белем бирү оешмасы;

түләү алучы – түләү бирү өчен конкурс нигезендә сайлап алуда (алга таба – сайлап алу) җиңүче дип танылган түләү алырга теләүче.

3. Түләү бирү максаты – муниципаль гомуми белем бирү оешмасында, дәүләт гомуми белем бирү оешмасында «укытучы» яки дәүләт һөнәри белем бирү оешмасында «мөгаллим» вазыйфаларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында, дәүләт гомуми белем бирү оешмаларында, дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучыларга ясалма интеллект нигезләрен өйрәтү түгәрәге эшчәнлеген гамәлгә ашыруда катнашучы хезмәткәрләрен стимуллау һәм аларга ярдәм күрсәтү.

4. Түләү Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучы буларак әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатка түләү бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән, бюджет акчасы белән баш эш итүче функцияләрен гамәлгә ашырган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан түләү алучыга бирелә.

5. Түләү бер тапкыр 258 624 сум күләмендә бирелә.

Түләү алу хокукы түбәндәгеләргә бирелә:

муниципаль гомуми белем бирү оешмалары, дәүләт гомуми белем бирү оешмалары укытучыларына – 239 түләү;

дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары мөгаллимнәренә – 100 түләү.

Түләү сайлап алу нәтиҗәләре буенча бирелә.

Түләү бирү эшен оештыру Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла һәм сайлап алуны үткәрү буенча конкурс комиссиясе (алга таба – комиссия) турындагы нигезләмәне һәм комиссия составын, сайлап алуда катнашуга заявкалар кабул итүне һәм теркәүне гамәлгә ашыручы операторны (алга таба шул ук эзлеклелектә – заявка, оператор), ясалма интеллект нигезләрен өйрәтү түгәрәге эшчәнлеген оештыру буенча түләү алырга теләүченең индивидуаль уку-укыту планы (алга таба – индивидуаль уку-укыту планы) формаларын, түләүләр бирү турында килешү (алга таба – килешү) формаларын, 2026 елда сайлап алуны уздыру срокларын, сайлап алу критерийларын Министрлык боерыгы (алга таба – сайлап алу турында боерык) белән раслаудан гыйбарәт.

Сайлап алуны үткәрү турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында (алга таба – сайт) урнаштырыла.

## II. Сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр

6. Түләү алырга теләүче түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

түләү алырга теләүче эш бирүчедә хезмәт шартнамәсе нигезендә төп эш урыны буенча атнага кимендә 18 сәгать күләмендә яки төп эш урыннан тыш атнага кимендә 9 сәгать күләмендә «укытучы», «мөгаллим» вазыйфалары буенча педагогик эшчәнлек гамәлгә ашыра;

заявка бирү датасына карата түләү алырга теләүченең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентларны түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмый;

заявка бирү һәм аны карап тикшерү датасына карата түләү алырга теләүче БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

заявка бирү һәм аны карап тикшерү датасына карата түләү алырга теләүче экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган физик затлар исемлегендә тормый;

заявка бирү һәм аны карап тикшерү датасына карата түләү алырга теләүче «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

заявка бирү һәм аны карап тикшерү датасына карата түләү алырга теләүче әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максат өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча

алмый.

## III. Түләү бирү тәртибе һәм шартлары

7. Грант бирү шартлары:

сайлап алуда җиңү;

түләү алучы тарафыннан эш бирүчедә килешү төзелгән датадан алып кимендә бер ел эчендә төп эш урыны буенча кимендә бер тариф ставкасы күләмендә яки төп эш урыннан тыш атнага кимендә 9 сәгать күләмендә «укытучы» яки «мөгаллим» вазыйфаларында хезмәт эшчәнлеген һәм килешү төзелгән датадан алып кимендә бер ел эчендә ясалма интеллект нигезләрен өйрәтү түгәрәге эшчәнлеген башкаруны гамәлгә ашыра;

түләү алучының урта һөнәри һәм (яки) югары белем турындагы документы эш бирүчедә укытыла торган укыту предметына һәм педагогик эшчәнлегенә туры килү.

8. Министрлык заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү максатларында комиссия төзи, аның составы кимендә биш әгъзадан (рәис, рәис урынбасарын һәм секретарьне кертеп) тора. Комиссия составына Министрлык вәкилләре, Гомумроссия мәгариф һөнәр берлегенең Татарстан республика оешмасы вәкилләре керә, шулай ук республика башкарма хакимият органнары, башка органнар һәм оешмалар вәкилләре, мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге белгечләр кертелергә мөмкин.

9. Министрлык сайтта түбәндәгеләрне чыгаруны тәэмин итә:

заявкалар кабул ителә башлау датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турында белдерү; анда заявкалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану даталары, заявка составында тапшырыла торган документлар исемлеге белән заявка формалары, заявкалар бирү адресы һәм ысулы;

заявкалар кабул ителә башлау датасына кадәр 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, сайлап алу турында боерык;

заявкалар кабул ителә башлау датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, оператор, аның урнашу урыны, электрон почта адресы, оператор вәкиленең элемтәгә керү өчен телефон номеры турында белешмәләр;

расланган датасыннан алып өч эш көне эчендә комиссия беркетмәсе.

10. Заявкаларны кабул итү һәм теркәү өчен Министрлык тарафыннан ул гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган оешмалар арасыннан оператор билгеләнә.

11. Сайлап алуда катнашу өчен түләү алырга теләүчеләр операторга сайлап алу турында боерык белән расланган форма буенча заявка һәм түбәндәге документларны тапшыра:

түләү алырга теләүченең законнар нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы;

түләү алырга теләүченең Россия Федерациясе гражданы паспорты күчермәсе;

белем турында һәм (яки) квалификация турында диплом күчермәсе;

эш бирүченең җитәкчесе яисә эш бирүченең башка вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе яисә түләү алырга теләүченең мәҗбүри пенсия иминияте һәм мәҗбүри социаль иминият системаларында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында

билгеләнгән тәртиптә алынган грант алырга теләүченең хезмәт эшчәнлеге һәм хезмәт стажы турында белешмә;

эш бирүче яисә эш бирүченең башка вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган, кәгазь һәм (яисә) электрон чыганакларда булган түләү алырга теләүченең һөнәри казанышлары турында мәгълүмат (раслый торган документлар күчермәләрен теркәп);

индивидуаль уку планы;

түләү алырга теләүче тарафыннан төп эш урыны буенча атнага кимендә 18 сәгать күләмендә яки төп эш урыннан тыш атнага кимендә 9 сәгать күләмендә «укытучы», «мөгаллим» вазыйфалары буенча хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында эш бирүче боерыгыннан өземтә;

салымнар, җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият җыемнары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау турындагы белешмә кәгазе.

Сайлап алуга бирелгән заявка һәм документлар түләү алырга теләүчеләргә сайлап алу тәмамланганнан соң кире кайтарылмый.

Түләү алырга теләүче тапшырыла торган документларның һәм заявкаларның дөреслеге өчен җавап бирә.

Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләре күрсәтелеп тапшырыла һәм оператор тарафыннан таныклана.

Заявка бирүче, операторга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, заявка белән шәхесен таныклый торган документ күрсәтә.

12. Операторга кергән заявка һәм аның составында бирелгән документлар урнашу урыны буенча операторга алар кергән датадан алып бер эш көне эчендә теркәлә. Заявка почта аша җибәрелгән очракта, заявка оператор тарафыннан почта бүлегендә алынган көннән алып бер эш көне эчендә теркәлә. Заявка электрон почта адресы буенча бирелгән очракта, оператор заявканы операторның электрон почта адресына кергән көннән алып бер эш көне эчендә терки.

Бер көнне кергән заявкаларга теркәү номерлары аларның керү вакытын исәпкә алып бирелә. Сайлап алуны уздыру турында белдерүдә билгеләнгән заявкаларны кабул итү срогы тәмамланганнан соң җибәрелгән заявкалар теркәлми һәм карап тикшерелми.

Түләү алырга теләүчеләрнең әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен, шулай ук әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән, түләү алырга теләүчеләр тарафыннан тапшырылган документларның тулы комплектта булуын тикшерү (алга таба – туры килүне тикшерү) оператор тарафыннан сайлап алу турында боерык белән расланган заявкаларны кабул итү һәм теркәү срогы тәмамланган көннән соң килә торган иң күбе өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла һәм сайлап алуда катнашырга рөхсәт ителгән заявкалар, шулай ук, әлеге Тәртипнең 14 пунктында билгеләнгән сайлап алуда катнашуга кертелмәү нигезләре күрсәтелеп, сайлап алуда катнашуга кертелмәгән заявкалар турында белешмәләр комиссиягә тапшырыла.

13. Комиссия заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән алып 10 эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 11 пункты нигезендә тапшырылган заявкаларны, документларны карап тикшерү, бәяләү һәм сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләүне

гамәлгә ашыра.

Заявканы карап тикшергәндә комиссия әгъзасының мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яисә читләтеп шәхси кызыксынуы барлыкка килгәндә, комиссия әгъзасы комиссия утырышы башланган датага һәм (яисә) вакытка кадәр бу хакта комиссия рәисенә, ә ул булмаганда комиссия рәисе урынбасарына язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта комиссиянең тиешле әгъзасы әлеге заявканы карап тикшерүдә катнашмый.

14. Түләү алырга теләүчегә сайлап алуда катнашырга рөхсәт бирмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Тәртипнең 11 пунктында каралган заявка һәм документлар тапшырылмау (тулы комплектта тапшырылмау), яки алар әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәү;

түләү алырга теләүче тарафыннан тапшырылган мәгълүмат дөрес булмау;

заявкаларны һәм (яки) документларны заявкалар кабул итү срогы тәмамлану датасыннан һәм (яки) вакытыннан соңрак тапшыру;

түләү алырга теләүчеләрнең әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә, әлеге Тәртипнең 7 пунктындагы дүртенче абзацында билгеләнгән түләү бирү шартларына туры килмәү фактын билгеләү.

Түләү алырга теләүчегә сайлап алуда катнашырга рөхсәт ителмәгән очракта, оператор заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килә торган эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә түләү алырга теләүчегә заявкада күрсәтелгән электрон почта адресына, сайлап алуда катнашырга рөхсәт бирмәү нигезләрен күрсәтеп, бу хакта хәбәрнамә җибәрә.

15. Сайлап алу түбәндәге этапларны үз эченә ала:

сайлап алу турында боерык белән билгеләнгән критерийлар буенча һөнәри-психологик әңгәмә узу;

шәхси уку планын карау һәм бәяләү.

16. Сайлап алу йомгаклары буенча әлеге Тәртипнең 15 пунктында каралган барлык сайлап алу этаплары буенча җыелган баллар кими бару тәртибендә түләү алырга теләүчеләрнең рангларга бүленгән исемлеге төзелә. Сайлап алуда җиңүчеләр дип сайлап алу йомгаклары буенча иң күп балл җыйган һәм түләү алырга теләүчеләрнең рангларга бүленгән исемлегендә (алга таба – рангларга бүленгән исемлек) муниципаль гомуми белем бирү оешмалары, дәүләт гомуми белем бирү оешмалары укытучылары арасында 1 урыннан 239 урынга кадәр һәм дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары мөгалимнәре арасында 1 урыннан алып 100 урынга кадәр алган түләү алырга теләүчеләр танылa.

Әгәр түләү алырга теләүчеләр бертөрле санда баллар җыйса, рангларга бүлү профессиональ-психологик әңгәмә нәтиҗәләре буенча җыйган иң күп балл буенча башкарыла.

Түләү алырга теләүчеләрнең баллары һәм һөнәри-психологик әңгәмә нәтиҗәләре буенча баллар тигез булган очракта, җиңүче әлеге Тәртипнең 17 пункты нигезендә комиссия тарафыннан сайлап алуның барлык этаплары йомгаклары буенча бер үк санда балл җыйган түләү алырга теләүчеләр ачыклангannнан соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә торган ачык тавыш биреп билгеләнә.

Рангларга бүленген исемлек комиссия беркетмәсенә теркәлә һәм аның аерылгысыз бер өлеше булып тора.

17. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының (комиссия рәисен яки ул булмаганда комиссия рәисе урынбасарын кертеп) гомуми саныннан яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы дип санала. Комиссия карары комиссия әгъзаларының күпчелеге аның өчен тавыш биргән очракта кабул ителгән дип санала.

Комиссия утырышында комиссия рәисе булмаган очракта, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

Тавышлар тигез булганда комиссия рәисенең тавышы, ә ул булмаганда комиссия рәисе урынбасары хәлиткеч булып тора. Комиссия карары комиссия утырышы беркетмәсе (алга таба – комиссия беркетмәсе) белән рәсмиләштерелә, аңа комиссия рәисе яисә ул булмаганда комиссия рәисе урынбасары һәм комиссия секретаре тарафыннан кул куела.

Комиссия беркетмәсенә комиссия карарын кабул итү датасыннан алып ике эш көне эчендә, әмма әлеге Тәртипнең 13 пунктында билгеләнгән сроктан да соңга калмыйча кул куела.

18. Министрлык, комиссия беркетмәсенә кул куелган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, сайлап алуда җиңүчеләргә түләүләр бирү яисә түләү бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Министрлык, карар кабул итү датасына түләү бирүдән баш тарту өчен түбәндәге нигезләр булганда, түләү бирүдән баш тарту турында карар кабул итә:

сайлап алуда җиңүче тарафыннан эш бирүче белән «укытучы» яисә «мөгаллим» вазыйфалары буенча хезмәт шартнамәсе өзелгән һәм әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән сроклар эчендә Министрлык тарафыннан түләү бирү турында карар кабул ителгәнгә кадәр башка эш бирүче белән «укытучы» яисә «мөгаллим» вазыйфалары буенча хезмәт шартнамәсе төзелмәгән;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты ачыкланган;

сайлап алуда җиңүче террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле физик затлар исемлегенә кертелгән;

сайлап алуда җиңүче экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган физик затлар исемлегенә кертелгән;

сайлап алуда катнашучы «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тора.

Түләү бирүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Министрлык түләү бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә сайлап алуда җиңүчегә аның заявкада күрсәтелгән электрон почта адресына хәбәр хаты җибәрү юлы белән, түләү бирүдән баш тарту нигезләрен күрсәтеп, хәбәрнамә җибәрә.

## IV. Килешү төзү тәртибе

19. Министрлык комиссия беркетмәсе нигезендә, Министрлык тарафыннан түләү бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, сайлап алу турындагы боерык белән расланган форма буенча түләү алучы белән килешү төзи.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

түләү бирү максаты һәм шартлары;

түләү күләме;

түләү күчерү сроклары һәм тәртибе;

Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан түләү алучының түләү бирү шартлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерү үткәрүгә ризалыгы;

түләүне кире кайтару очраклары һәм тәртибе;

түләүне мәҗбүри түләтү буенча чаралар күрү сроклары;

түләү бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык;

түләү алучының эш бирүчедә килешү төзелгән датадан алып бер ел эчендә «укытучы» яки «мөгаллим» вазыйфаларында төп эш урыны буенча кимендә бер тариф ставкасы күләмендә яки төп эш урыннан тыш атнага кимендә тугыз сәгать күләмендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруга йөкләмәсе;

түләү алучының килешү төзелгән көннән алып кимендә бер ел дәвамында ясалма интеллект нигезләрен өйрәтү түгәрәге эшчәнлеген башкаруны гамәлгә ашыру йөкләмәсе;

килешү төзелгән датадан алып бер ел үткәнгә кадәр эш бирүче белән хезмәт шартнамәсе өзелгән очракта, хезмәт мөнәсәбәтләре туктатылган датадан алып өч эш көненнән соңга калмыйча, түләү алучының Министрлыкка хәбәр итү йөкләмәсе.

20. Тапшырылган документлар килешү төзелгән вакыттан алып биш ел дәвамында сакланырга тиеш.

21. Министрлык, түбәндәге нигезләр булганда, килешүне өзү турында һәм түләү бирү турындагы карарны гамәлдән чыгару турында карар кабул итә:

эш бирүче белән хезмәт шартнамәсен әлеге Тәртипнең 7 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән сроктан алданрак өзү (әлеге Тәртипнең 26 пунктында каралган очрактан тыш);

түләү алучы әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән срок җиткәнгә кадәр ясалма интеллект нигезләрен өйрәтү түгәрәге эшчәнлеген гамәлгә ашыруны туктату;

түләү алучыны әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы дүртенче, бишенче абзацларында күрсәтелгән физик затлар исемлегенә кертү һәм (яки) түләү алучыны «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты дип тану;

килешү төзелгән датадан алып түләү күчерелгән датага кадәр чорда әлеге Тәртипнең 11 пунктында билгеләнгән, түләү алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның һәм документларның дөрес булмау фактын билгеләү.

Министрлык килешүне өзү хакында һәм түләү бирү турындагы карарны гамәлдән чыгару хакында кабул ителгән карар турында түләү алучыга аны кабул иткән датадан алып өч эш көне эчендә түләү алучының заявкада яисә килешүдә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча хәбәр итә.

22. Министрлык түләү алучы тарафыннан түләү бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

23. Түләү алучыларга түләү бирү Министрлык тарафыннан түләү алучыларның Россия кредит оешмаларында ачылган счетларына акча күчерү юлы белән башкарыла.

24. Түләү алучы, түләү биргәндә билгеләнгән тәртип, шартлар бозылган, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булган очракта, Министрлыкның язма таләбен алган көннән 30 календарь көн эчендә түләүне Татарстан Республикасы бюджетына ирекле рәвештә тулы күләмдә кире кайтара.

Министрлык яисә дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан түләү алучының әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы өченче абзацында каралган (әлеге Тәртипнең 27 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш) шартларны үтәмәү факты билгеләнгән очракта, түләү аны алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы өченче абзацында каралган шарт түләү алучы тарафыннан үтәлмәү срогына пропорциональ күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

25. Татарстан Республикасы бюджеты кеременә әлеге Тәртипнең 24 пунктында билгеләнгән түләү ирекле рәвештә кире кайтарылудан баш тартылган очракта, Министрлык әлеге акчаны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

26. Түләү алучы, түбәндәге шартлар үтәлгәндә, хезмәт эшчәнлеген үтәү урынын үзгәртергә мөмкин:

хезмәт шартнамәсе өзелгән датадан алып бер айдан да соңга калмыйча, башка эш бирүчегә эшкә урнашу;

төп эш урыны буенча атнага кимендә 18 сәгать күләмендә яки төп эш урыннан тыш атнага кимендә 9 сәгать күләмендә «укытучы», «мөгаллим» вазыйфалары буенча хезмәт эшчәнлеген башка эш бирүчедә гамәлгә ашыру һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының, дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының, дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларының белем алучылары өчен ясалма интеллект нигезләрен өйрәтү түгәрәге эшчәнлеген оештыру.

Хәрби хезмәткәрнең, махсус хәрби операциядә катнашучының ире (хатыны) яшәү урынын алыштыруга бәйле рәвештә, әлеге Тәртипнең җиденче пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән срок чыкканга кадәр түләү алучы тарафыннан эш бирүче белән хезмәт шартнамәсе өзелгән очракта, шулай ук эш бирүче бетерелгән очракта түләү кире кайтарылмый.

27. Түләүне максатчан файдалануны, аны бирү шартлары һәм тәртибе үтәлешен контрольдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.